**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2020 Балык Бистәсе штп. № 110пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге хакында” 2014 елның 9 сентябрендәге 161пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны “Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. “Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге турында” Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 9 сентябрендәге 161пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.07.2015 195пи, 17.08.2016 №133пи, 18.10.2017 № 226пи, 17.04.2018 № 72пи, 22.10.2019 № 296пи, 04.03.2020 № 40пи, 17.04.2020 № 81пи карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) әлеге карарга кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының, предприятиенең, учреждениенең, башка оешманың үз аталышы һәм мәгълүматның вывескасында башка урнаштырылырга тиешле мәгълүматлары күрсәтелгәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.6, 2.8, 2.14, 2.16,2.17 3.2 – 3.8, 3.10

(гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 5.1, 5.2, 5.6 (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә башкарыла торган муниципаль ташуларга карата) маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар исемлеге";

1.2) түбәндәге әчтәлектәге VII пункт белән тулыландырырга:

"VII. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.17 маддәсендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле урындагы затлар:

- "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе башлыгы;

- "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Сатып алулар һәм муниципаль контроль идарәсе" муниципаль казна учреждениесенең административ-техник инспекциясе бүлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Сатып алулар һәм муниципаль контроль идарәсе" муниципаль казна учреждениесенең административ-техник инспекциясе бүлеге баш белгече (инспекторы) ;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы урынбасары;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов